ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422150

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яшьлек ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Карар | Постановление
“22” ноябрь 2018 ел. | № 17

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы белән, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән «19» ноябрь 2018 елдагы № 903 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Дүсмәт авыл җирлеге
Башкарма комитет
җитәкчесе О.Н.Павлов

Татарстан республикасы
Мамадыш муниципаль
районы, Дүсмәт авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2018 елның
22 ноябренең 17 нче№ лы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы,
Дүсмәт авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы, Дүсмәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019 нчы елның 28 нче февраленә кадәр, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә яраксыз булу,

б) эш урыныннан командировкада булу,

гражданнарга гариза нигезендә бер айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарынамуниципаль берәмлекнең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгаруһәм халыкка җиткерү Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыуставында бигеләнгән тәртиптә,шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыруяки почта элемтәсе аша юллау юлы белән житкерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге

буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл жирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 22 нче ноябре 17 нче № лы карарына 2 нче кушымта

Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________________________________

Адрес: _______________________________________________________________________

Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 903 нче номерлы "Дүсмәт авыл җирлеге территориясендә 2018 нче елның 18 нче ноябрендә үткәрелгән референдум нәтиҗәләре турында" карары нигезендә Сезгә 2019 нчы елның 28 нче февраленә кадәр 2018 нче елның 18 нче ноябре Дүсмәт авыл җирлеге территорясендәге референдум чарасын гамәлгә ашыру буенча 400 сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

ТР, Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге УФК по РТ ( РТ Мамадыш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы)

Кабул итүче як банкы Отделение-НБ Республика Татарстан БИК 049205001

Кабул итеп алучы Сч. № 40101810800000010001

ИНН 1626008921

КПП 162601001

КБК 60511714030100000180 ОКТМО 92638415

Түләүнең билгеләнеше узара салым

Җитәкче ___________________ _О.Н.Павлов________

М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне 400 сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.

Түләүченең Ф.И.Ә.и.___________________________________________________________

Адрес:________________________________________________________________________

Кабул ителде «__» ________________ 20__ ел.

_________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Дүсмәт җирлеге башкарма комитетында кала.*